**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**НУРЛАТСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ГЛАВА ЕЛАУРСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**ЕЛАУР АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Елаур авылы КАРАР

«30» октябрь 2019 ел № 2

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлегенең Сосновка авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, муниципаль районның Елаур авыл җирлеге Уставының 23 статьясын гамәлгә ашыру максатларында, Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2019 елның 13 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлеге Сосновка авылы Үзәк урам , 19 йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында, Үзәк урам буенча 1-27 йортлардан, Кирпичное авылы Тынычлык урамы буенча 3-15 йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Елаур авыл җирлегенең Сосновка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1нче төркем инвалидлардан, балачак инвалидларыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, 500 сум сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы?:

1) Су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр башкару.

2) Урамнарны яктырту (ремонт, яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру).

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны «Интернет «мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Елаур авыл җирлегенең Сосновка авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

7. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Елаур авыл җирлеге башлыгы О.В.Охотникова